РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**посёлка городского типа**
**КАМСКОЕ УСТЬЕ**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Советска, 11, пгт. Камское Устье, 422820
тел. (884377) 2-19-40, 2-15-76, факс: (884377) 2-14-76
ОКПО 78692631, ОГРН 1051651018484
ИНН/КПП 1622004531/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Кама Тамагы**
**шәһәр тибындагы поселогы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 11,Кама Тамагы штп, 422820,
тел. (884377)2-19-40, 2-15-76, факс: (884377) 2-14-76
ОКПО 78692631 ОГРН 1051651018484
ИНН/КПП 1622004531/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«6 » сентябрь, 2019 ел № 120

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел, № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогының яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән ташламалы категориядән тыш ( беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, биш һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган, көндезге формада белем алучы студентлар булган күпбалалы гаиләләр) 2020 елга 300 сум күләмендә җыярга һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:
-Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселок зиратына керү юлларын төзекләндерү;

- ясалма тигезсезлекләр урнаштыру, юл билгеләре сатып алу һәм урнаштыру ;

- Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы эчендәге һәм урамара юлларны ремонтлау;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-ТР, Кама Тамагы штп,Совет ур.,11 йорт,МСУ диварына;

-ТР, Кама Тамагы штп,К.Маркс ур.,105 йорт,библиотека , шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
"Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы"
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Яруллин